РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                   КАРАР

07.12.2020                с. Куралово                54

Социаль әһәмиятле объектларның, кешеләр күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен әзерләү һәм үткәрү чорында гражданнарның җәмәгать иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябреннән 131-ФЗ Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994нче елның 21нче декабреннән 69-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июленнән 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2020-2021нче елларның Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен бәйрәм итү чорында дәүләт һәм муниципаль милекне янгыннардан саклау максатыннан,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге халкы тарафыннан пиротехника әйберләрен махсус куллану урыннарын билгеләргә:

- Куралово авылы (Сулица елгасы тугае, үзәк юлдан уң һәм сул як)
- Рус Бурнашы авылы (Большая урамында урнашкан Сулица елгасы тугае)

2. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, Раштуа бәйрәмнәрен үткәрү вакытында социаль - әһәмиятле объектларны саклауны көчәйтү буенча җаваплы зат итеп Куралово авыл җирлеге Башлыгы В. А. Квашневаны билгеләргә.

3. Әлеге карарны Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Куралово авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе Т. Ю. Тимиряева